Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2023 ел № 78

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 93 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Клементейкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 93 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» карарына (Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2019 елның 13 декабрендәге 111 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 126 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтаның «Җирлек башкарма комитеты вәкаләтләре» 4 бүлегенең 4.1 пунктында:

1.1.1. 2 пунктчаны түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац белән тулыландырырга:

«-полициянең участок вәкаләтлесе вазифасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазифаны биләү чорына торак бина бирә;»

1.1.2. 6 пунктчаның сигезенче абзацын төшереп калдырырга;

1.1.3. 9 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, авыл җирлеге яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра.»;

1.1.4. 11 пунктчага түбәндәге эчтәлекле сигезенче, тугызынчы, унынчы абзацлар өстәргә:

«- алкогольле, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра;

- муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы гамәлгә куя;

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра.».

1.2. 3 пунктчаның өченче абзацында «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Клементейкино авылы, Үзәк урам, 38а йорт, Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38а йорт, Яңа Чишма авылы, Гафиатуллин урамы, 3а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Клементейкино авыл
җирлеге башлыгы Л.Э. Языков